**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Илбәк авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Илбәк авылы №26 03 март 2016 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының 2012 елның 18 апрелендәге 35 номерлы карары белән расланган Илбәк авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлегендә гавами тыңлаулар үткәрү срокларын төгәлләштерү максатларында

Илбәк авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының 2012 елның 18 апрелендәге 35 номерлы карары белән расланган Илбәк авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә, 4.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«4.3. Гавами тыңлаулар уздыру турындагы карар гавами тыңлаулар уздыру көненә кадәр 15 көннән дә соңга калмыйча җирлек Советы яисә җирлек башлыгы тарафыннан кабул ителә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Илбәк авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис: Л.Р. Әсәдуллина